**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 28 августындагы 2986 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2026 елның 9 апрелендәге 1136 номерлы «1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 81 еллыгын, Россия көнен, Татарстан Республикасы көнен һәм Казан шәһәре көнен, Яңа ел белән бәйле чараларны, бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның тууына 140 ел тулуны бәйрәм итүгә багышланган чараларны әзерләү һәм уздыру чорында Казан шәһәренең автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны вакытлыча чикләү турында »гы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 маендагы 372 номерлы «Төбәк әһәмиятендәге яки муниципальара, җирле әһәмияттәге автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен вакытлыча чикләүне яисә вакытлыча туктатып торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында»гы карары нигезендә **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2026 елның 9 апрелендәге 1136 номерлы «11941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 81 еллыгын, Россия көнен, Татарстан Республикасы көнен һәм Казан шәһәре көнен, Яңа ел белән бәйле чараларны, бөек татар шагыйре Габдулла Тукайның тууына 140 ел тулуны бәйрәм итүгә багышланган чараларны әзерләү һәм уздыру чорында Казан шәһәренең автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен һәм аларны куеп торуны вакытлыча чикләү турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. түбәндәге эчтәлекле 1.2.4 пунктын өстәргә:

«1.2.4. кыска вакытлы аренда хезмәте күрсәтә торган электр самокатлары (WHOOSH һәм МТС.URENT) һәм велосипед («Яшел шәһәр») операторлары

белән берлектә әлеге карарның 1-5 кушымталарында күрсәтелгән участокларда шәхси мобильлек чараларын куеп торуны һәм аларның хәрәкәтен тыю эшен оештырырга»;

1.2. 3 номерлы кушымтаны гамәлдән чыккан дип танырга;

1.3. әлеге карарның кушымтасын Казан шәһәре Башкарма комитетының 2026 елның 9 апрелендәге 1136 номерлы карарына 3 номерлы кушымта дип санарга;

1.4. әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.С.Шакировка йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 28 августындагы
2986 номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы көнен һәм**
**Казан шәһәре көнен бәйрәм итү бәйрәм итүгә багышланган**
**чараларны әзерләү һәм уздыру чорында Казан шәһәренең**
**автомобиль юлларында транспорт чаралары хәрәкәтен һәм**
**аларны куеп торуны вакытлыча чикләү графигы**

| № т/б | Датасы һәм вакыты | Ябу урыны |
|---|---|---|
| 1 | 2026 елның 27 августында<br>00.00 сәгатьтән<br>2026 елның 31 августында<br>23.59 сәгатькә кадәр<br>(кирәк булганда) | Сибгат Хәким урамы буенча<br>(Декабристлар урамыннан<br>Әпсәләмов урамына кадәр);<br>«Казан» гаилә үзәге янындагы территория<br>(парковка зонасы);<br>Бондаренко урамы буенча (Солдат урамыннан<br>Сибгат Хәким урамына кадәр) |
| 2 | 2026 елның 28 августында<br>20.00 сәгатьтән<br>2026 елның 31 августында<br>11.00 сәгатькә кадәр<br>(кирәк булганда) | Шиһабетдин Мәрҗани урамы (Татарстан<br>урамыннан Нурсолтан Назарбаев урамына<br>кадәр);<br>Каюм Насыйри урамы (Татарстан урамыннан<br>Фатыйх Кәрим урамына кадәр);<br>Зәйни Солтан урамы (Габдулла Тукай<br>урамыннан Каюм Насыйри урамына кадәр) |
| 3 | 2026 елның 30 августында<br>18.00 сәгатьтән<br>2026 елның 30 августында<br>23.59 сәгатькә кадәр<br>(кирәк булганда,<br>шәһәр җәмәгать транспорты<br>маршрутларыннан кала) | Батурин урамы (Большая Красная<br>урамыннан Кремль яр буе урамына<br>кадәр ике юнәлештә);<br>Меңьеллык мәйданыннан Батурин урамына<br>чыгу юлы |
| 4 | 2026 елның 24 августында<br>07.00 сәгатьтән<br>2026 елның 30 августында<br>18.00 сәгатькә кадәр<br>(кирәк булганда) | Кремль урамы (Астрономия урамыннан<br>Беренче Май мәйданына кадәр), шул<br>исәптән Профсоюз урамына кадәр Иван<br>авышлыгы |
| 5 | 2026 елның 24 августында<br>07.00 сәгатьтән<br>2026 елның 31 августында<br>18.00 сәгатькә кадәр (кирәк<br>булганда) | Федосеев урамы (Батурин урамыннан Япеев<br>урамына кадәр) |

| | | |
|---|---|---|
| 6 | 2026 елның 30 августында<br>00.00 сәгатьтән 23.59 сәгатькә кадәр (кирәк булганда) | «Казан» халыкара ат спорты комплексы янындагы парковка зонасының барлык территориясендә, шул исәптән Альберт Камалиев проспектыннан алып Альберт Камалиев проспектындагы 27р номерлы йортка кадәр автомобиль юлы буйлап |
| 7 | 2026 елның 1 маеннан<br>2026 елның 15 октябренә кадәр<br>(кирәк булганда) | Тихомирнов урамын һәм Петербург урамын тоташтыручы автомобиль юллары |

___________________